| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабря 2024 г. с.Шалты № 112

Шалты авыл җирлегенең 2025 елга
һәм 2026 һәм 2027 еллар план
чорына бюджеты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1 нче статья

1. Шалты авыл җирлеге бюджетының 2025 елга төп характеристикаларын casларга:

1) Шалты авыл җирлеге бюджетының гомуми керем күләме 5 207,7 мең сум;

2) Шалты авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгым күләме 5 207,7 мең сум;

3) Шалты авыл җирлеге бюджет дефицитының гомуми күләме 0 мең сум.

2. Шалты авыл җирлеге бюджетының 2026 һәм 2027 елларга төп характеристикаларын расларга:

1) Шалты авыл җирлеге бюджетының гомуми керем күләме 2026 елга 5 297,8 мең сум һәм 2027 елга 5 387 мең сум;

2) Шалты авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгым күләме 2026 елга 5 297,8 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган 127,4 мең сум күләмендә чыгымнар, һәм 2027 елга 5387,0 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган 259,0 мең сум күләмендә чыгымнар;

3) Шалты авыл җирлеге бюджет дефицитының гомуми күләме 2026 елга 0 мең сум һәм 2027 елга 0 мең сум.

3. 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Шәле авыл җирлеге бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларг.

2 нче статья

1. 2026 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә муниципаль эчке бурычның югары чиген расларга.

2. 2027 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә муниципаль эчке бурычның югары чиген расларга.

3. 2028 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә муниципаль эчке бурычның югары чиген расларга.

3 нче статья

Шалты авыл җирлеге бюджетында әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

4 нче статья

1. 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына Шалты авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына Шалты авыл җирлеге бюджеты чыгымнарын классификацияләү чыгымнары төрләренең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне расларга.

3. Шалты авыл җирлеге бюджетының 2024 елга 0 мең сумлык, 2025 елга 0 мең сумлык, 2026 елга 0 мең сумлык җәмәгать норматив йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга.

5 нче статья

1. Җирлек бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен 2025 елга 2 602,9 мең сум, 2026 елга 2 602,9 мең сум, 2027 елга 2 602,9 мең сум күләмендә җирлек халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру чараларын тәэмин итү буенча төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга расларга.

2. Баулы муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

6 нчы статья

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясы нигезендә җирлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен 2,5 мең сум итеп расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

7 нче статья

Шалты авыл җирлеге бюджетында Баулы муниципаль районы бюджетыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә 2025 елга 4 077,7 мең сум, 2026 елга 4 147,7 мең сум, 2027 елга 4 225,7 мең сум күләмендә алына торган дотацияләрне исәпкә алырга.

8 нче статья

Шалты авыл җирлеге бюджетында елда җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәп-хисапны гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына Баулы муниципаль районы бюджетыннан алына торган 2025 елда 183,0 мең сум, 2026 елда 200,1 мең сум, 2027 елда 207,3 мең сум субвенцияләрне исәпкә алырга.

9 нчы статья

Шалты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2025 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә.

10 нчы статья

2025 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджеты акчаларының калдыклары 2024 елда шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты исеменнән төзелгән муниципаль контрактларга түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыклары суммасыннан артмаган күләмдә, 2025 елда Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлтелә.

11 нче статья

Татарстан Республикасы Баулы районының Финанс министрлыгының Казначылык Департаменты территориаль бүлеге төзелгән килешүләргә ярашлы рәвештә Шалты авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

12 нче статья

Әлеге карарны мәгълүмат стендында игълан итәргә һәм Шалты авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

13 нче статья

Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе Фаткуллин З.Х.